**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 27 декабрь номер 2436

# КАРАР

**Яңа ел чараларын уздыру объектларында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү һәм пиротехник әйберләрдән файдалану һәм янгынга каршы махсус режим билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 ноябрендәге 1082 номерлы карары нигезендә, яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышының һәм сәламәтлегенең, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында»1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы белән, карар бирәм**:**

**1.** 2024 елның 25 декабреннән 2025 елның 08 гыйнварына кадәр Лаеш муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

**2.** Махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда түбәндәге чикләрдә урнашкан территорияләрдә 3 класслы хәвефлелектәге пиротехник эшләнмәләрдән файдалануны тыю билгеләргә:

- сәнәгать, транспорт инфраструктурасы объектлары чикләреннән (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы чикләреннән 500 метр ераклыкта;
- торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары чикләреннән, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары, хосусый йортлар чикләреннән 30 метр ераклыкта;
- Күпфатирлы торак йортлардан 30 метр ераклыкта.

**3.** Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

массакүләм чаралар үткәрелгән урыннарда гражданнарның иҗтимагый иминлеген һәм террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итү;

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру урыннарында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;

бәйрәм чаралары уздырыла торган урыннарда янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга, су чыганакларына килү юлларын кардан чистартуны оештырырга;

шәхси автотранспортны турыдан-туры янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары янына куймау турында халыкка хәбәр итәргә;

пиротехника әйберләрен куллану урынын карар белән билгеләргә, 30- һәм 500-метрлы зоналарда пиротехника әйберләрен махсус янгынга каршы режим вакытында куллану тыелган өстәмә объектларны билгеләргә, янгын сүндерү өчен беренчел чаралар белән тәэмин итәргә;

халык, юридик затлар арасында, шул исәптән пиротехник эшләнмәләр белән ваклап сату белән шөгыльләнүче, шулай ук пиротехник әйберләрне сатканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен аңлату эшләре уздыруны оештырырга;

урам чыршыларын бизәү сыйфатында сертификацияләнгән электр гирляндаларын гына файдалану;

кешеләр куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын үтәүне тикшерергә авыл җирлекләре хезмәткәрләре арасыннан җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә.

**4.** Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**5.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**